КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 13 сентябрь г.Казань № 863

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2023 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 18 декабрь, 1006 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2023 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 18 декабрь, 1006 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 7 октябрь, 731 нче; 2014 ел, 29 ноябрь, 930 нчы; 2014 ел, 12 декабрь, 982 нче; 2015 ел, 4 август, 566 нчы; 2015 ел, 5 сентябрь, 640 нчы; 2016 ел, 27 сентябрь, 689 нчы; 2017 ел, 24 апрель, 241 нче; 2017 ел, 28 июнь, 450 нче; 2018 ел, 26 июнь, 520 нче; 2018 ел, 19 декабрь, 1173 нче; 2019 ел, 2 сентябрь, 754 нче; 2020 ел, 28 гыйнвар, 47 нче; 2020 ел, 16 июль, 601 нче; 2021 ел, 29 апрель, 297 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2014 – 2023» саннарын «2014 – 2025» саннарына алмаштырырга;

1 пунктта «2014 – 2023» саннарын «2014 – 2025» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «2014 – 2023 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасында (алга таба – Программа):

исемендә «2014 – 2023» саннарын «2014 – 2025» саннарына алмаштырырга;

Программа паспортында:

«Программа исеме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программа исеме | «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасы (алга таба – Программа)»; |

«Программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары | 2014 – 2025 еллар, шул исәптән:<br>I этап: 2014 – 2016 еллар;<br>II этап: 2017 – 2025 еллар»; |

«Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары</td>
<td>
<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th colspan="2">Карала торган акча күләме, млн.сум</th></tr>
<tr><th>Татарстан Республикасы бюджеты</th><th>федераль бюджет</th></tr>
<tr><td>2014</td><td>39,324</td><td>21,6008</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>32,724</td><td>17,96775</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>42,624</td><td>18,2494</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>40,371</td><td>9,1068</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>52,2787</td><td>10,3585</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>53,6144</td><td>10,8317</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>26,5596</td><td>10,5074</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>48,2286</td><td>10,2759</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>55,7786</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>49,6686</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>55,0786</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>48,6886</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>544,9387</td><td>108,89825</td></tr>
</table>
Программаны финанслауның гомуми күләме 653,83695 млн. сум тәшкил итә, шулардан:<br>
544,9387 млн.сумы – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы;<br>
108,89825 млн.сумы – федераль бюджет акчасы.<br>
Искәрмә. Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле финанс елына һәм план чорына тиешле дәрәҗәләрдәге бюджетларны формалаштыруны, шулай ук Программа чараларын финанслашуга федераль бюджеттан акча бүлеп бирүне исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»;
</td>
</tr>
</table>

«Программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр һәм социаль-икътисадый нәтиҗәлелек күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр һәм социаль-икътисадый нәтиҗәлелек күрсәткечләре | Татарстан Республикасында милләтара мөнәсәбәтләр торышын уңай бәяләүче республика халкы өлеше 83,4 процент күрсәткеченә ирешәчәк;<br>Татарстан Республикасында конфессияара мөнәсәбәтләр торышын уңай бәяләүче республика халкы өлеше – 85,4 процент;<br>башка милләт вәкилләренә карата толерантлы мөнәсәбәт дәрәҗәсе – 95 процент;<br>гомумроссия гражданлык тәңгәллеге дәрәҗәсе – 81 процент;<br>Татарстан тәңгәллеге дәрәҗәсе – 81 процент;<br>үз-үзенә карата милли билге буенча дискриминация булмавын билгели торган гражданнар өлеше – 93,5 процент;<br>чит ил гражданнарына тискәре мөнәсәбәт кичермәгән гражданнар өлеше – 81,2 процент;<br>гражданлык бердәмлеген ныгытуга һәм милләтара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучылар саны – 74 370 кеше, шулардан 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге яшьләр саны – 51 980 кеше;<br>Россия халыкларының этномәдәни үсешенә һәм телләрнең күптөрлелегенә ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучылар саны – 560 170 кеше, шулардан 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге яшьләр саны – 165 190 кеше;<br>рус телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен саклап калуга һәм үстерүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучылар саны – 131 720 кеше;<br>Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте өлкәсендәге проектларны һәм программаларны гамәлгә ашыру барышында кулланыла торган халыкларның телләре саны – 36;<br>милли рухи-агарту эшчәнлеге өлкәсендә коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан үткәрелгән чаралар саны – 1 950;<br>мигрантларны социаль һәм мәдәни адаптацияләүгә һәм интеграцияләүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучылар саны – 4 050 кеше;<br>Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру өчен җаваплы булган һәм өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча укыган дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәткәрләр саны – кимендә 100;<br>Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрендә гражданнар бердәмлеген саклауга һәм этносара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерүгә юнәлдерелгән программаларны тормышка ашыручы Татарстан Республикасы муниципаль |

| | |
|---|---|
| | берәмлекләре саны – 45»; |

Программаның II бүлегендә:

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программаны тормышка ашыру вакыты: 2014 – 2025 еллар.»;

егерме беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II этап (2017 – 2025 еллар). II этапның максаты – I этапта формалашкан уңай тенденцияләрне үстерү һәм ныгыту (Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерү өлкәсендә тотрыклы уңай нәтиҗәләргә ирешүне кертеп).»;

Программаның IV бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IV. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программа чараларын финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырылачак.

Программада программа чараларын тормышка ашыру өчен бюджеттан тыш акча (эшмәкәрләр, иганәчеләр акчасы) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетлары акчасын җәлеп итү мөмкинлеге каралган.

| Ел | Карала торган акча күләме, млн.сум | |
|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы бюджеты | федераль бюджет |
| 2014 | 39,324 | 21,6008 |
| 2015 | 32,724 | 17,96775 |
| 2016 | 42,624 | 18,2494 |
| 2017 | 40,371 | 9,1068 |
| 2018 | 52,2787 | 10,3585 |
| 2019 | 53,6144 | 10,8317 |
| 2020 | 26,5596 | 10,5074 |
| 2021 | 48,2286 | 10,2759 |
| 2022 | 55,7786 | - |
| 2023 | 49,6686 | - |
| 2024 | 55,0786 | - |
| 2025 | 48,6886 | - |
| Барлыгы | 544,9387 | 108,89825 |

Программаны финанслауның гомуми күләме 653,83695 млн.сум тәшкил итә, шулардан:

544,9387 млн.сумы – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы;

108,89825 млн.сумы – федераль бюджет акчасы.»;

Программага 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

Программага $1^1$ нче кушымтада:

нумерация башисемендә «2014 – 2023» саннарын «2014 – 2025» саннарына

алмаштырырга;

исемендә «2014 – 2023» саннарын «2014 – 2025» саннарына алмаштырырга;

беренче абзацта «2014 – 2023» саннарын «2014 – 2025» саннарына алмаштырырга;

Программага 3 нче кушымтада:

нумерация башисемендә «2014 – 2023» саннарын «2014 – 2025» саннарына алмаштырырга;

исемендә «2014 – 2023» саннарын «2014 – 2025» саннарына алмаштырырга;

Программага 4 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин